БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 02 2022 ел № 129

Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның "21" 02
129 номерлы карарына
кушымта

Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе

1. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан (алга таба текст буенча - Балтач муниципаль районы) субсидияләр бирү максатларын, шартларын, тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

– мөрәҗәгать итүчеләр - субсидияләр алуга дәгъвачылар яисә әлеге Тәртип таләпләре нигезендә субсидия алу турында гаризаны һәм аңа документларны тапшыруга вәкаләтле башка затлар;

– субсидия алучы - әлеге Тәртип таләпләре нигезендә исәп-хисап счетларына вәкаләтле орган һәм әлеге мөрәҗәгать итүче арасында төзелгән субсидия бирү турында килешүне үтәү өчен (яисә субсидия бирү турында вәкаләтле орган карарын үтәү өчен) акчалар күчерелгән мөрәҗәгать итүче.

1.3. Транспорт оешмаларына субсидия бирүнең максаты - пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү белән бәйле булган пассажирлар йөртүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү (алга таба текст буенча - Субсидияләр).

1.4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе - Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, бюджет акчаларын алучы буларак, аңа билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган).

1.5. Субсидия бирү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты турында карарда каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларда гамәлгә ашырыла.

1.6. Тиешле финанс елына бюджетта каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлекчәсендә ачылган вәкаләтле органның шәхси счетында исәпкә алына.

1.7. Субсидияләр алу хокукына ия мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

– дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелгән башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә халыкка даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм

багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт төзегән транспорт оешмалары булырга.

– Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашырырга.

1.8. Субсидия аны алучы субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган көнгә кадәр 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

субсидия алучыларның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

Балтач муниципаль районы бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты алдында вакыты чыккан башка бурыч юк;

субсидияләр алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору (сайлап алуда катнашучы юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп корудан тыш), ябылу процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар-шәхси эшкуарлар шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

квалификациясен югалткан затлар реестрында квалификациясен югалткан җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булган сайлап алуда катнашучы баш бухгалтер, шәхси эшкуар һәм сайлап алуда катнашучы булган товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында мәгълүматлар юк;

чит ил юридик заты, шулай ук теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын кулланучы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) булган чит ил юридик затларының устав (җыелма) капиталында катнашу өлеше, тулаем алганда, 50 проценттан артык булган россия юридик заты булып тормый;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан акча алучы булып тормый.

## 2. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе;

2.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) гаризаны тапшыру көнендә беркетеп бирелгән документлар белән субсидия бирү турында гаризаны кабул итүне һәм журналда теркәүне гамәлгә ашыра; журнал номерлап чыккан, тегелгән (шнурланган) һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш.

2.2. Гаризаны карау буенча җаваплы: Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Икътисад һәм фаразлау бүлеге (алга таба - Икътисад һәм фаразлау бүлеге)

2.3. Субсидияләр алу өчен, субсидия алучылар Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыралар:

– 1 нче кушымта нигезендә формада субсидия бирү турында гариза;

– субсидия алучының оештыру документларының, шулай ук аларга карата барлык үзгәрешләр турында документларның күчермәләрен;

– субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имза куйган оешманың әлеге Тәртипнең 1.8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында белешмәне;

– Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләрне;

– автоматлаштырылган тәртиптә, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, аерым әйткәндә, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга, субсидия бирү максатларында җыюны, яздыруны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләүне, тапшыруны (шәхси мәгълүматларны таратуны, шәхессезләндерүне, ябуны, шәхси мәгълүматларны юк итүне) дә кертеп, автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чараларны кулланмыйча шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләргә (операцияләргә) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасына ризалык;

– субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне гамәлгә ашыруга ризалык;

– пассажирлар йөртү буенча эшчәнлек алып баруга лицензия күчермәсен;

– тиешле субсидия турында белешмә-исәп;

– QR-кодларны тикшерү өчен җаваплы затның билгеләнүе турында раслый торган документлар;

– QR-кодларны тикшерү өчен җаваплы затның эшкә урнашуын раслый торган документлар.

2.4. Субсидия алучы үз инициативасы буенча түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

– салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычларның булмавын раслый торган документны;

– юридик затны дәүләт теркәвенә алынуы турында таныклык күчермәсен яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан теркәлү кәгазен;

– салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

– Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Субсидияләр алучы әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Башкарма комитет күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тәкъдим ителгән документларның күчермәләре субсидияләр алучы тарафыннан таныклана.

2.5. Икътисад һәм фаразлау бүлеге әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшерә,

2.6. Икътисад һәм фаразлау бүлеге Башкарма комитеттан документлар һәм материаллар кабул иткәннән соң, аларны карый һәм субсидия бирү мөмкинлеге турында карар чыгара яисә, сәбәпләрне күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарта.

2.7. Икътисад һәм фаразлау бүлегенең уңай карары булганда, баш бүлүче 10 эш көне дәвамында субсидия бирү турында шартнамә төзи һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Балтач районы буенча Казначылык департаментының Территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан субсидия алучының исәп-хисап счетларына субсидия күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидия бирү турында шартнамә 1 елга гамәлдә булу вакыты белән төзелә.

2.8. Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә Икътисад һәм фаразлау бүлеге тарафыннан субсидия алучыга язмача рәвештә тиешле карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә саналган өч көн эчендә җибәрелә.

2.9. Субсидия бирү турында хәбәр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамланганчы кимендә 15 көн кала урнаштырыла.

2.10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

– субсидия алучының әлеге Тәртипнең 1.7 һәм 1.8 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

– субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

– субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

– бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамәдә баш тартуның нигезләре күрсәтелә.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидия субсидия бирү турында гариза тапшыру чираты тәртибендә бирелә.

2.11. Мөрәҗәгать итүче тапшырыла торган мәгълүматның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

2.12. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән субсидияне бирү максатлары белән билгеләнә һәм түбәндәге чыгымнар юнәлешләре буенча гамәлгә ашырыла:

– машина йөртүчеләрнең һәм кондукторларның хезмәт хакы;
– иминият кертемнәре.

2.13. Россия Федерациясе валютасы законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлау эшләнмәләрен сатып алганда (китергәндә) башкарыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү максатларына ирешүгә бәйле рәвештә, субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы алу тыела.

## 3. Хисап бирүгә таләпләр.

3.1. Күрсәткечләргә ирешү турында хисаплылыкка таләпләр, аерым алганда, субсидия алучы тарафыннан күрсәткечләргә ирешү турында хисап бирү тәртибен, вакытларын һәм формасын билгеләү билгеләнми.

## 4. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылык турында таләпләр.

4.1. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны бюджет акчаларын алучы буларак Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты башкара.

4.2. Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерә.

4.3. Бюджет акчаларын алучы һәм муниципаль финанс контроленең вәкаләтле органы буларак баш булүче, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны субсидия алучы тарафыннан бозулар булган очракта, бирелгән субсидия кире кайтарылырга тиеш.

4.4. Бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнә субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү фактларын ачыклау буенча Башкарма комитетның тиешле таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

4.5. Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

4.6. Бирелә торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә. Хокук бозучыларга гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе ___________________________

______________________________________
(оешманың атамасы, ОГРН, ИНН )

адресы: ________________________

Гариза

Сездән Пассажирларда яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуны яисә соңгы алты ай эчендә әлеге авыруны кичерү фактын раслый торган QR - кодлар булуын, коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация ясауга медицина ягыннан каршылыклар булуны раслаучы гамәлдәге шәхси QR - кодлар булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү өчен ____________________________________ (__________________________________________________________________________________ _____) сум күләмендә субсидияләр бирүегезне сорыйм

Белешмә-хисап беркетелә.

Субсидияләрне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм:

Субсидия алучы: __________________________________________________

ИНН/КПП:_____________________________

р/с: __________________________________________________

Банк исеме __________________________________________________

корр. счет ____________________________________________

БИК __________________________________________

ОКТМО __________________________________________

Урнашу урынының адресы: ______________________________________________

Фактта урнашу урыны адресы: ___________________________________

Җитәкченең элемтә телефоны________________________________________

E-mail: ___________________________________

Кушымта:

1.______________________

2.______________________

3.______________________

4.______________________

__________________/__________________
(җитәкченең имзасы) ФИА (дата) Мөһер

"___"_________ 202_ ел